4.6. Бәйге нәтиҗәләре буенча карар чыгару буенча бәйге комиссиясе утырышы турыдан-туры/читтән торып үткәрелә.

Министрлык Бәйгедә катнашучылардан бәйге материалларын кабул итү тәмамланган көннән соңгы киләсе ике эш көне эчендә аларны бәйге комиссиясе әгъзаларына җибәрә.

Бәйге комиссиясе әгъзалары, бәйгедә катнашучыларның тәкъдим ителгән бәйге материалларын карап, аларны алу көненнән соңгы биш эш көне эчендә Министрлыкка, әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә күрсәтелгән бәяләү нигезләре нигезендә баллар биреп, бәйге материалларына карата үзләренең билгеләрен җибәрә.

Министрлык бәйге материалларын бәйге комиссиясе әгъзаларына җибәргән көннән соңгы тугыз эш көне эчендә:

бәйге комиссиясе әгъзалары тарафыннан һәр атама юнәлеш буенча җиңүчеләрне билгеләп, бәйге материалларына бирелгән бәяләрнең җыелма таблицасын төзи;

бәйге комиссиясе карары проектын әзерли һәм аны, раслау өчен, бәйге комиссиясе рәисенә җибәрә.

Бәйгедә җиңүчеләр бәйгедә катнашучы җыйган балларны кушу юлы белән билгеләнә.

Һәр атама юнәлештә иң күп балл җыйган катнашучы Бәйгедә җиңүче дип таныла.

Бәйге эшләре буенча тупланган баллар бер үк санда булса, тавыш бирү игълан ителә. Карар утырышта катнашкан бәйге комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, рәислек итүче затның тавышы хәлиткеч булып тора.

4.7. Бәйге комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул бәйге комиссиясе рәисе тарафыннан Министрлык тарафыннан карары проекты бәйге комиссиясе рәисенә тәкъдим ителгән көннән соңгы ике эш көне эчендә раслана.

Бәйге комиссиясенең беркетмәсе Министрлык сайтында (http://mpt.tatarstan.ru) «Эшчәнлек» - «Энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру» «Бәйгеләр» - «Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм предприятиеләрнең матбугат хезмәтләре арасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм пропагандалау буенча ел саен үткәрелә торган республика бәйгесе» бүлегендә аны раслаган көннән соң бер эш көне узганчы урнаштырыла.

4.8. Бәйгедә җиңүчеләр истәлекле бүләкләр һәм дипломнар белән бүләкләнә.

4.9. Бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләү энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру республика программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен карау турында Татарстан Республикасы Хөкүмәте утырышы кысаларында гамәлгә ашырыла.

## 5. Бәйгене матди тәэмин итү күләмнәре һәм чыганаклары

2023 елда Бәйгедә җиңүчеләрне бүләкләү күләме һәм чыганаклары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән билгеләнә.

